ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь, 2016 ел № 13/12

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының 2005 елның 30 декабрендәге «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 144-ЗРТ санлы Законы нигезендә, Башкарма комитетның Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимен караганнан соң,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/11 санлы Карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) комиссия составыннан чыгарырга:

- Вафин Рафик Нургаяз улын;
- Шаһвәлиев Айрат Гыйлметдин улын;

2) комиссия составына кертергә:

- Вәлиева Эльвира Гафур кызын – Башкарма комитетның Комсомол районы хакимиятенең территориядәге оешмалар белән үзара эшчәнлек бүлеге башлыгын;
- Мәүҗүтов Әнвәр Әнәс улын – административ комиссия әгъзасын.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ